**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 4 май № 280

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 1 июнь, 395 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру турында хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру турында хисаплылык кертү тәртибен һәм формасын билгеләү хакында» 2013 ел, 20 декабрь, 965н боерыгын, Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондының «Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру максатларына акчадан файдалану турында хисаплылык кертү тәртибен һәм формасын билгеләү хакында» 2013 ел, 26 ноябрь, 237 нче боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы

сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2016 ел, 12 апрель, 215 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 1 июнь, 395 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру турында хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 – 4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5 сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры тарафыннан билгеләнгән вазыйфаи затларга имзага түбәндәге хисапларны кертә:

Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондының (алга таба – ММИФФ) «Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру максатларына акчадан файдалану турында хисаплылык кертү тәртибен һәм формасын билгеләү хакында» 2013 ел, 26 ноябрь, 237 нче боерыгында билгеләнгән форма нигезендә Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру максатларына акчадан файдалану турында (әлеге боерыкның 2 нче кушымтасындагы 2 бүлек);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру турында хисаплылык кертү тәртибен һәм формасын билгеләү хакында» 2013 ел, 20 декабрь, 965н боерыгы белән билгеләнгән тәртип һәм форма буенча Ярдәмче программада билгеләнгән эшләрне башлау һәм тәмамлау вакытларына кагылышлы өлештә Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру барышы хакында (әлеге боерыкның 2 нче кушымтасындагы 1 нче таблица);

Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте тарафыннан

билгеләнгән тәртип һәм форма буенча Татарстан Республикасында перинаталь үзәк төзелешен һәм эксплуатациягә кертүне тикшерүдә тоту турында.

Хисаплар, ММИФФ һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күчүне һәм алардан файдалануны раслый торган һәм таныкланган документлар күчермәләрен, шул исәптән башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актны теркәп, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мөһере белән таныклана.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек министрлыгы түбәндәгеләрне тапшыра:

ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 5 сенә кадәр, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм форма буенча Татарстан Республикасында перинаталь үзәк төзелешен һәм эксплуатациягә кертүне тикшерүдә тоту турында хисап;

ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 сына кадәр, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан кертелгән Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру чыгымнарының аңлатмасын теркәп, ММИФФ билгеләгән тәртип һәм форма буенча Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру максатларына акчадан файдалану турында хисап;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртип һәм форма буенча Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру барышы хакында хисап.

4. Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, ММИФФ билгеләгән тәртип һәм форма нигезендә Россия Федерациясе субъектлары сәламәтлек саклау системасын модернизацияләү буенча төбәк программаларын тормышка ашыру максатларына акчадан файдалану турында хисапны Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына кертүне тәэмин итә.».

2. Бу карар аңа кул куйган үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\280.doc